ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 74 (I өлеш), № 93) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19 һәм 20 пунктлар өстәргә:

«19) концессия килешүләре нигезендә яисә үтәү йөкләмәләре Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән заем шартнамәсе буенча алынган акчалардан файдаланып булдырылган һәм 2024 елның 1 декабреннән 2025 елның 31 декабренә кадәр файдалануга тапшырылган гомуми файдаланудагы региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларына һәм күрсәтелгән автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булып торучы корылмаларга карата. Гомуми файдаланудагы региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль

юлларының, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булып торучы корылмаларга керә торган мөлкәт исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Салым ташламасы объект файдалануга тапшырылган айның 1 числосыннан башлап җиде елга бирелә;

20) Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистика мәгълүматын формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белешмәләре буенча халык саны 7 мең кешегә кадәр булган шәһәрләрдә урнашучы, югары белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан файдаланылучы уку-лаборатория корпуслары булган объектларга карата.»;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16) 2029 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 20 пунктын.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 19 пункты нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 20 пункты нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 19 февраль
№ 6-ТРЗ